# ГАЛӘМ

**февраль**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
«ЮЛСУБИНО ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ» ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

**№6**



27 НЧЕ ЯНВАРЬ-ЛЕНИНГРАД БЛОКАДАСЫ ӨЗЕЛГӘН КӨН.ШУЛ УҢАЙДАН СУГЫШ ЧОРЫ БАЛАЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР ОЕШТЫРЫЛДЫ.БУ ФОТОДА СЕЗ СУГЫШ ЧОРЫ БАЛАСЫ ГАТИЯТОВА БИБИНУР АПА БЕЛӘН ОЧРАШУ МИЗГЕЛЛӘРЕН КУРӘСЕЗ. УЛ УКУЧЫЛАР БЕЛӘН БАЛАЧАК ХАТИРӘЛӘРЕН УРТАКЛАШТЫ, МАТУР ТЕЛӘКЛӘРЕН ҖИТКЕРДЕ.



КЫЗГАНЫЧ, КАЙБЕР СЫЙНЫФЛАРДА ҺАМАН ТАКТА СӨРТЕЛМИ,СУ АЛЫШТЫРЫЛМЫЙ КАЛГАН ОЧРАКЛАР КАБАТЛАНА.ТЕЛӘСӘ НИЧЕК ТӘРТИПСЕЗ ЯТКАН КИЕМНӘРНЕ КУРГӘЧ БИГРӘК КУҢЕЛСЕЗ. МОНДЫЙ КУРЕНЕШЛӘР БИГРӘК ТӘ 5 НЧЕ СЫЙНЫФЛАРДА КУЗӘТЕЛДЕ. УЗЕБЕЗНЕҢ ВАЗИФАЛАРНЫ ОНЫТМЫЙЧА ВАКЫТЫНДА БАШКАРЫП БАРСАК ИДЕ.МОНЫҢ ӨЧЕН КУП ВАКЫТ ТА КИРӘКМИ БИТ ИНДЕ ЮГЫЙСӘ...




БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНЫҢ ДАНЛЫКЛЫ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН БЕРСЕ БУЛЫП СТАЛИНГРАД СУГЫШЫ ТОРА. БУ СУГЫШТА ҖИҢҮГӘ ДӘ 75 ЕЛ ТУЛДЫ. Сталинград өчен барган сугышларда Кызыл Армия 600 меңнән артык кешесен (үлүчеләр һәм яралылар), немецлар 700 меңләп кеше югалталар. Шәһәр тулысынча җимерелә һәм кирпеч ватыкларыннан, вак ташлардан, тимер-томыр өемнәреннән торган хәрабәләргә әверелә. Сталинград өчен барган сугышлар тәмамланганда аның 500 мең кешелек халкыннан (100 меңләп кеше эвакуацияләнергә өлгерә) 30 мең чамасы кеше, шәһәрнең үзәк өлешендә исә нибары 7 кеше исән кала. 1942 елда булдырылган «Сталинград оборонасы өчен» медале белән 700 меңнән артык кеше бүләкләнә.



9 ФЕВРАЛЬ МӘКТӘБЕБЕЗДӘ 5-6 СЫЙНЫФЛАР ӨЧЕН “БАТЫРЛЫК “ТЕМАСЫНА СЫЙНЫФ СӘГАТЕ ҮТКӘРЕЛДЕ.ӘЛЕГЕ СЫЙНЫФ СӘГАТЕН ТАРИХ УКЫТУЧЫСЫ БАДАМШИНА Ф.Ф. ҮТКӘРДЕ. УКУЧЫЛАРГА КЫЮ , ТӘВӘККӘЛ, НЫК ИХТИЯРЛЫ КЕШЕ НИНДИ БУЛУЫН АҢЛАТЫП КИТТЕ. ҮЗЕҢДӘ БАТЫРЛЫК, КЫЮЛЫК, ТӘВӘККӘЛЛЕК СЫЙФАТЛАРЫ ТӘРБИЯЛӘҮ ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘРГӘ КИРӘКЛЕГЕ ТУРЫНДА ДА СӨЙЛӘДЕ.

**КОТЛЫЙБЫЗ!**
**СӘМРУХ ЕЛ ПРЕМИЯСЕ СӘЛӘТНЕҢ ЕЛ БУЕ БАРГАН ЭШЕНӘ НӘТИҖӘ ЯСЫЙ. ӘЛЕГЕ ПРЕМИЯ ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫНДА БЕЗНЕҢ МӘКТӘБЕБЕЗ КЫЗЛАРЫ ДА КАТНАШТЫ.КАРИМУЛЛИНА ГӨЛЗИДӘ “ЕЛ СӘЛКЕШЕ”НОМИНАЦИЯСЕНДӘ ФИНАЛИСТ БУЛДЫ.КОТЛЫЙБЫЗ,ГӨЛЗИДӘ! (ПРЕМИЯ ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫ Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФИЛАРМОНИЯ КОНЦЕРТЛАР ЗАЛЫНДА ҮТТЕ.)**






“ТАТАРСТАН ЧАҢГЫ ЮЛЛАРЫ–2018”
ЧУЛМАН ЯРЫ ЯЛ ПАРКЫНДА “ТАТАРСТАН ЧАҢГЫ ЮЛЛАРЫ–2018” МАССАКҮЛӘМ ЯРЫШЛАРЫ БУЛЫП УЗДЫ. ТАБИГАТЬ ТӘ СПОРТ СӨЮЧЕЛӘРГӘ, ТАМАШАЧЫЛАРГА КОЯШЛЫ МАТУР КӨНЕН БҮЛӘК ИТТЕ.ӘЛЕГЕ ЯРЫШТА БЕЗНЕҢ МӘКТӘПТӘН ДӘ ШАРАФИЕВР.И.ЖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ ЯШЬ СПОРТЧЫЛАР КАТНАШТЫ.ФИЗИК ТӘРБИЯ УКЫТУЧЫСЫ РАФИК ИЛЬЯСОВИЧ ҮЗ ЯШЕНДӘГЕЛӘР АРАСЫНДА 4 УРЫННЫ ЯУЛАДЫ.КОТЛЫЙБЫЗ!

«СОЗВЕЗДИЕ-ЙОЛДЫЗЛЫК» ФЕСТИВАЛЕНӘ САЙЛАП АЛУ ТУРЛАРЫ ДА БАШЛАНЫП КИТТЕ. УЛ 1 ФЕВРАЛЬДӘН АЛЫП МАРТ АХЫРЫНА КАДӘР ДӘВАМ ИТӘЧӘК.
9 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ КҮГӘРЧЕН МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫНДА ЗОНА ЭТАПЫ БУЛЫП УЗДЫ.МӘКТӘБЕЗДӘН МУСТАФИНА АЙСЫЛУ, МУБАРАКОВА ИЛҮЗӘ ҺӘМ ЗӘМИРӘЛӘР, ФАРЗУТДИНОВА ГУЗӘЛ,ГАРИПОВ САЛАВАТЛАР ӘЛЕГЕ САЙЛАП АЛУ ТУРЫНДА КАТНАШТЫ.АЛГА ТАБА ДА УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ АЛАРГА.
“ИҢ ЯХШЫ СЫЙНЫФ ҖИТӘКЧЕСЕ” БӘЙГЕСЕ
10 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ ТАРИХ ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ ТЕЛЕ УКЫТУЧЫСЫ БАДАМШИНА ФӘЙРУЗА ФАРЗЕТДИН КЫЗЫ “ИҢ ЯХШЫ СЫЙНЫФ ҖИТӘКЧЕСЕ ”БӘЙГЕСЕНДӘ КАТНАШТЫ. АФӘРИН!



# *Җәлил истәлеге*

15 нче февраль көнне мәктәбебездә бөек язучы Муса Җәлилнең тууының 112 еллыгын багышлнган чара узды. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Илзирә Исхаковна җитәкчелегендә 8 сыйныф укучылары Т. Миңнуллинның “Моңлы бер җыр” әсәреннән өзек куйдылар.






# *Мәктәптә семинар*

16 февраль көнне мәктәбебездә ”Инновационная деятельность педагога в условиях внедрения и реализации ФГОС” темасы буенча физика укытучылары семинары булып үтте. Мәктәбебез директоры, Гарипов Нияз Ильяз улы, 7 сыйныф укучылары белән дәрес үткәрде. Бу семинарга районның барлык физика укытучылары жыелган иде.

# *Әфган сугышы күңелдә*

14 февраль көнне мәктәптә 7 сыйныф укучылар өчен Рәмзия Исхак кызы “Әфганстана-йөрәк ярасы” темасына ачык сыйныф сәгате үткәрде. Укучылар әлеге фаҗиганең зурлыгын аңлап , анда булган солдатларның батырлыкларына таң калдылар. Чынлыкта да нәк менә шушындый дәресләр киләчәк буынны үткән белән тоташтыручы җеп булып торалар



Ватанны саклаучылар көне

21 нче февраль көнне Ватанны саклаучылар көне уңаеннан мәктәбебездә "Ягез әле,егетләр!"чарасы булып узды.Егетләребез тырыша-тырыша көч сынаштылар.Чара бик куңелле үтте.





МӘКТӘПТӘ СЕМИНАР

20 НЧЕ ФЕВРАЛЬ КӨННЕ МӘКТӘБЕБЕЗДӘ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ СЕМИНАР КИНӘШМӘСЕ БУЛЫП УЗДЫ.АНДА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕН ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП УКЫТУ ПРОБЛЕМАСЫ КҮТӘРЕЛДЕ.ШУЛ УК КӨННЕ ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ УНАЕННАН, АВЫЛДАШЫБЫЗ, ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН ҺӘМ АНЫҢ ЯШЬ КАЛӘМДӘШЛӘРЕ ФӘНИЛ ГЫЙЛӘҖЕВ ҺӘМ ЯКТАШЫБЫЗ СИРИНӘ МӨХӘММӘТҖАНОВА БЕЛӘН ОЧРАШУ БУЛЫП УЗДЫ.

Кышкы сабантуй

24 нче февральдә авылда “Сәламәтлек көне” уңаеннан чана-чаңгы шуу, әрвахларга дога кылу чарасы оештырылды. Оештыручылар, катнашучылар зират тавына җыелдылар. Һәр кеше әлеге чарада рәхәтләнеп катнашты: чаңгыда, чанада, аэрочаналарда ярышты.
Көннең матурлыгы да искитәрлек булды: салкынча, кояшлы, җилсез. Чараны оештыручылар Хәкимовлар гаиләсе, тәмле пылау, кайнар чәй белән сыйлаучы Наилә, Гөлсәрия, Резедә, Гүзәлияләргә, авыл егетләренә , гомумән, чара оештыруга өлеш керткән һәр кешегә Аллахның олы рәхмәтләре яусын!

